| СОВЕТ НИЖНЕУСЛОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |
| 25.11.2021 | 16-91 |

с. Нижний Услон

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең Түбән Ослан авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Уставының 24 ст. туры китереп,

Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге торак пункт территориясенең бер өлешендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 6 декабренә билгеләргә.
2. Түбән Ослан авылының Дзержинский урамы 43 нче йорт адресы буенча гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2022 нче елда Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлеге Түбән Ослан авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 5650 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме:

- күпфатирлы йортта канализация агынтык суларын биологик чистарту станциясен сатып алу һәм урнаштыру;

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын Түбән Ослан авылы Дзержинский урамы 43 нче йорт

янында 09.00 сәгатьтә үткәрергә.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Түбән Ослан авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы С.А.Казанцев